# Barısı Da Bezdä

**AIGEL (АИГЕЛ)**

Cilderäbez tönlä utırıp
Häy, tuqta-ta-ta maşina
Übeşäbez artta qotırıp
Taksiçı bezne quma-quma

Tägärmäç cirne äyländerä
İreklek başnı äyländerä
Aldıbızda nurlı irtägä
Ozatalar menep kirtägä

Prezident, patriarx, uçastkovıy, partkom
Äläkçe, kremlebot häm propagandon
Zet-cırçı, divan ğäskärläre
Häm Roskmnadzor xezmätkärläre

U-u yätim qala watan, tuqta, nadan! Qaya kitä!
Eteş-törteş - artıq tırış bu xalıqtan awa kirtä

U-u yätim qala watan, tuqta, nadan! Qaya kitä!
Eteş-törteş - artıq tırış bu xalıqtan awa kirtä (awa kirtä)

Bikli-bikli, bi-bikli bikli biklänä

Bezne bikli-bikli bi-bikli
Biklänä kürmägez
Bezne yota-yota-yota şartlamasın törmägez
Waqıtığıznı tuzdırasız waqıtıbıznı urlıy-urlıy bez
Nişläsägez dä barıber sezne üzebez belän almıybız

Oçabız taññan torıp
Häy, tuqta-ta-ta, samolet
Utırtqan qala utırıp
Yabışa qanatqa tonkiy lyod
Yabışa qanatqa mayor
Yabışa qanatqa vaxter
Yabışa qanatqa voyenkor
Tizlek arta
Pilot uynata hardcore

Kem ağulı orlıq sibär
Şul ağulı arış urır
Kem muyınnarnı sabınlar
Üze dä erep yuwılır
Kem hawanı qısıp totqan
Niçek sularğa onıtqan
Tawışıñnı cide qat sat
Ber qat teleñne kisep at

Bärä cillär bitlärebezgä
Färeştälär cilkälärebezdä
Närsä kiräk - barısı da bezdä
Närsä kiräk - barısı da bezdä

Bärä cillär bitlärebezgä
Färeştälär cilkälärebezdä
Närsä kiräk - barısı da bezdä
Närsä kiräk - barısı da bezdä

Tištěno z pisnicky-akordy.cz
Sponzor: www.srovnavac.cz - vyberte si pojištění online!